**ГЛАВА**
**РУССКО-ОШНЯКСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422642, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, Профсоюзная ул., дом 7а,
с.Русский Ошняк, 422642

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**РУС ӘШНӘГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

422642,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Профсоюз урамы, 7а нчы йорт,
Рус Әшнәге , 422642

**Тел.: (8-4361) 24643 , факс: (8-4361) 24643 , эл.адрес: Rosn.Rs@tatar.ru**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

. 2019 елның 18 октябре Рус Әшнәге авылы № 9

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Рус Әшнәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 30 октябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 30 октябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
4. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең Рус Әшнәге авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

Рус Әшнәге авылындагы мәктәп, кыр урамнарын ремонтлау

- Рус Әшнәге авылларында контейнер мәйданчыклары ясау һәм төзекләндерү; ;

- Рус Әшнәге авылы урамнарының машиналар йөрү өлешен (урамнарны чистарту) кышкы карап тоту;

- Рус Әшнәге авылында суүткәргеч ремонтлау;

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге башлыгы В.Х.Хаҗиев